КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 815

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым кате-горияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы; 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче; 2018 ел, 15 февраль, 90 нчы; 2018 ел, 24 март, 166 нчы; 2020 ел, 12 май, 379 нчы; 2021 ел, 17 февраль, 85 нче, 2022 ел, 7 март, 203 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бу Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү бу Нигезләмәнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидия алучыларның җыелма исемлеге, бу Нигезләмәнең 2 пунктындагы «б» пунктчасының икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидия алучыларның җыелма исемлеге һәм бу Нигезләмәнең 2 пунктындагы «б» пунктчасындагы бишенче, алтынчы абзацларында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидия алучыларның җыелма исемлеге (алга таба – җыелма исемлекләр) нигезендә чират буенча башкарыла; әлеге исемлекләр Министрлык тарафыннан гражданнар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак бу Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән срокларда исәпкә баскан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары исемлекләре нигезендә формалаштырыла.

Җыелма исемлекләр шул ук хронологик тәртиптә – гражданнарның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган тәртибендә формалаштырыла. Бер үк көнне исәпкә куелган гражданнар җыелма исемлектә алфавит тәртибендә күрсәтелә.

Министрлык Татарстан Республикасы муниипаль берәмлекләренең башкарма комитетларыннан исемлекләр кергән көннән 10 эш көне эчендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм Татарстан Республикасы ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең аңа тоташтырыла торган төбәк системасыннан файдаланып, бу системадан файдалану мөмкинлеге булмаганда – кәгазь чыганакларда, шәхси мәгълүматлар өлкәмендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварында 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә торак урыннарга мохтаҗ ветераннарны торак белән тәэмин итү буенча дәүләт социаль ярдәме чараларын күрсәтүгә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, әгәр дә субсидия алучы аны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алынган датага кадәр Россия Федерациясенең башка субъекты террориясендә яшәгән булса, бу Нигезләмәнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән субсидия алучы тарафыннан федераль бюджет акчасы исәбеннән торак урын белән тәэмин итү хокукын тормышка ашырылу турындагы белешмәләрне соратып ала.

Субсидияләрне чираттан тыш алу хокукына Бөек Ватан сугышы инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, хәрби хәрәкәтләрнең I төркем инвалидлары, шулай ук хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә алынган яралану, контузия яки гариплек нәтиҗәсендә I төркем инвалидка әверелгән эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм җитәкчелек составы затлары, шулай ук әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән торак урыннары билгеләнгән тәртиптә яшәү һәм ремонт ясау өчен яраксыз дип танылган яисә реконструкцияләнмәгән гражданнар категорияләре арасыннан субсидияләр алучылар һәм (яисә) Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формаларыннан интегүче затлар ия.

Субсидияләрне беренче чиратта алу хокукына хәрби хәрәкәтләрнең II, III төркем инвалидлары, шулай ук хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) башкарганда алынган яралану, контузия яки гариплек аркасында II, III төркем инвалидка әверелгән эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм җитәкчелек составы затлары, «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар һәм «Камалышта калган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә әгъзалары, җирле һава һөҗүменә каршы оборонаның объектлы һәм аварияле командаларының саклану төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган затларның гаиләләре әгъзалары, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләренең һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең гаиләләре әгъзалары, һәлак булган (вафат булган) хәрби хәрәкәтләр инвалидларының һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзалары, хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең, эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының гади һәм җитәкчелек составы затларының гаилә әгъзалары, әсирлектә һәлак булган, билгеләнгән тәртиптә хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип танылган хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары, инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр ия.

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда гамәлдәге армия составына кермәгән хәрби частьләрдә, учреждениеләрдә, хәрби уку-укыту йортларында кимендә алты ай хәрби хезмәт иткән хәрби хезмәткәрләр, әлеге чорда хезмәт итү өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр, шулай ук Бөек Ватан сугышы чорында һава һөҗүменә каршы оборона, җирле һава һөҗүменә каршы оборона объектларында, гамәлдәге фронтларның тыл чикләре кысаларында оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар, гамәлдәге флотларның операция зоналары төзелешендә, тимер һәм автомобиль юлларының фронт янындагы участокларда эшләгән затлар, Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында мәҗбүри тотып торылган транспорт флоты суднолары экипажлары үзләре биләгән хезмәт торак урыннарыннан чыгарылган очракта субсидияләр белән тәэмин ителә.

II, III төркемнәр хәрби хәрәкәтләр инвалидлары, шулай ук эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарының хәрби хезмәт йөкләмәләрен (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгәндә алынган яралану, контузия яки гариплек аркасында II, III төркемнәр инвалидлары булган хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм җитәкчелек составларындагы затлары арасыннан субсидияләр алучыларга I төркем инвалидлыгы бирелгән очракта, алар субсидияләрне чираттан тыш алу хокукын ала.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык өлешендә исемлекләрне актуальләштерүне гамәлгә ашырырга һәм гражданнарның субсидияләр алу хокукын үзгәртүгә китерә

торган хәлләр барлыкка килү турында мондый хәлләр ачыкланган көннән 10 эш көне эчендә Министрлыкка хәбәр итәргә бурычлы.

Министрлык җыелма исемлекләр нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган формага таянып, торак белән тәэмин итү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтелүгә хокуклы гражданнар исемлекләрен (алга таба – Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган формада төзелгән гражданнар исемлекләре) формалаштыра һәм аларны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне үтәп урнаштыра.

Җыелма исемлекләргә үзгәрешләр кертелгән очракта, Министрлык Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча төзелгән гражданнар исемлекләрен актуальләштерүне һәм аларны, һәр кварталның беренче аеның 5 көненнән дә соңга калмыйча, рәсми сайтта урнаштыруны гамәлгә ашыра.

Шул ук вакытта рәсми сайтта агымдагы календарь елда элек урнаштырылган гражданнар исемлекләренә барлык сылтамалар сакланып калырга тиеш.»;

5 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары беренчел исемлекләр кергән көннән алып биш эш көне эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә беренчел исемлекләргә кертелгән гражданнарга, законнар нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык турында хәбәр алынган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына мөрәҗәгать итү зарурлыгы турында хәбәр итә.

Әгәр граждан хәбәр алган көннән алып 30 көн эчендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны расламаган булса, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары бу хакта Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары тарафыннан торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны актуальләштерү уздырылган елдан соңгы елның 1 гыйнварына кадәр язма рәвештә хәбәр итә.»;

7 пунктта «бүленгән» сүзен «бүленә» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шартнамә буенча торак урынның кыйммәте субсидия күләменнән артыграк булган очракта, җитеп бетмәгән сумма гражданның үз акчасы һәм (яки) заем акчасы исәбеннән түләнергә тиеш. Әгәр торак урынның бәясе субсидия күләменнән кимрәк булса, сатып алынган торакның факттагы бәясе түләнергә тиеш.»;

күрсәтелгән Нигезләмәгә 1 нче кушымта исемендә «бүленгән» сүзләрен «бүленә» сүзләренә алмаштырырга;

бу Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 815 нче карары редакциясендә)

Форма

______________________________
**(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))**

______________________________
субсидия алучы ________ _ _

______________________

**яшәү урыны адресы______________**
______________________________
**шәхесне раслаучы документ:**
______________________________
**сериясе _________ № ______________,**
**кем тарафыннан бирелгән ________________________,**
**бирелү датасы ____________________**

Торак сатып алуга субсидия бирү турында хәбәрнамә

Сез торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга субсидия алу хокукына ия.

Әлеге хәбәрнамәне алган көннән алып бер ай эчендә Сезгә түбәндәге адрес буенча банк бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк:

______________________________________________________________
**(банкның исеме һәм адресы күрсәтелә)**
**аерым блокланган максатчан шәхси счет ачу өчен, соңыннан күрсәтелгән субсидия күчереләчәк.**

Торак сатып алуга субсидия буларак бирелә торган акчалар исәбеннән торак сатып алу максатларында Сез махсуслаштырылган оешма йә Татарстан Республикасында капиталь төзелеш объектларын төзүнең дәүләт заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыручы учреждение белән төзелгән килешүне, күчемсез мөлкәткә милек хокукының һәм аның белән алыш-бирешләрнең күчешен дәүләт

теркәвенә алучы орган нигезендә субсидия алучыга күчемсез милеккә милек хокукының күчүе теркәлгән үз фатирының булачак гражданинның катнашу, сайлау һәм аны тапшыру беркетмәсе яисә торак урынны сатып алу-сату шартнамәсе белән һәм күчемсез мөлкәт объектына милек хокукын теркәүне таныклый торган Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан һәм гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданының исәпкә алына торган субсидияне алучы буларак тәэмин итә торган өземтәне социаль яклауның территориаль органына тапшырырга тиеш, шуннан соң вәкаләтле банкта Сез ачкан счетка социаль яклауның территориаль органыннан Сезгә шартнамә бирү турында мәгълүмат алынган көннән алып 35 эш көне эчендә субсидия күләмендә финанс чаралары күчереләчәк.

Әгәр дә Сез алыш-бирешләр нәтиҗәсендә гомуми мәйданы торак урын сатып алу урынында җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданының исәпкә алу нормасыннан кимрәк тәшкил иткән торак урыннар милекчесе булсагыз, кечерәк мәйданлы торак урын сатып алу рөхсәт ителә.

Субсидияне Сез түбәндәгеләр өчен файдаланыла алмыйсыз:

якын туганнарыннан (иреннән (хатыныннан), бабасыннан, әбисеннән, оныкларыннан, ата-аналарыннан (шул исәптән уллыкка алучылардан), балалардан (шул исәптән уллыкка кызлыкка алынган), бертуган һәм бертуган булмаган абый-энеләрдән һәм апа-сеңелләрдән) торак урын сатып алу;

индивидуаль торак йортны (торак йортның бер өлешен (долясын)) әлеге йорт (торак йортның бер өлеше (долясы)) урнашкан һәм аны файдалану өчен кирәк җир кишәрлеге белән сатып алганда җир кишәрлегенә түләү.

Сатып алына торган торак мәйданы өчен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алуга субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 07 июнь, 275 нче карары нигезендә бүлеп бирелгән торак сатып алуга субсидияне исәпкә алып башкарылачак дигән пунктны килешүгә кертү кирәклегенә игътибар бирәбез.

Әгәр дә Сез субсидия алудан баш тартсагыз яки хәбәрнамә алган көннән алып өч ай эчендә торак шартларын яхшыртуга хокукыгызны гамәлгә ашырмаган очракта, Сез субсидия алуга дәгъва кылучылар исемлегеннән чыгарылачаксыз. Шул ук вакытта Сез федераль бюджет акчалары исәбеннән торак шартларын яхшырту хокукын югалтмаячаксыз һәм субсидия алучыларның җыелма исемлегеннән төшереп калмаячаксыз. Соңыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрелгән шәхси гаризагыз буенча Сез яңадан субсидияләр бүлеп бирелгән гражданнар исемлегенә кертеләчәксез.

Әлеге Хәбәрнамәнең тугызынчы абзацында билгеләнгән срок, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, торак шартларын яхшыртуга хокукны гамәлгә ашыру срокларын озайту өчен җитди сәбәпләр күрсәтеп, язма гариза биргән очракта, арттырылырга мөмкин.

Субсидия күләме __________ сум тәшкил итә.

(Субсидия күләме Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы субсидия алуга дәгъва кылучылар исемлеген юллаган көнгә гамәлдә булган субсидия алучы бер кешегә исәпләнгән гомуми торак мәйданы нормативы (18 кв. метр яисә 36 кв. метр - аерым категория ветераннар өчен) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв. метрының уртача базар бәясенә тигез).

Шартнамә буенча торак урынның кыйммәте субсидия күләменнән артыграк булган очракта, җитеп бетмәгән сумма гражданның үз акчасы һәм (яки) заем акчасы исәбеннән түләнергә тиеш. Әгәр торак урынның бәясе субсидия күләменнән кимрәк булса, сатып алынган торакның факттагы бәясе түләнергә тиеш.

Субсидия алуга риза, федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм аларны үтәргә йөкләмә алам.

______________________________________________________ / ____________________
**(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))** **(имзасы)**

**Субсидия алудан баш тартам** _________________________________________
___________________________________________________________________________
**(сәбәбен күрсәтергә)**

**Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе** _____________ _________________________
**(имза)** **(имзаны таркатып язу)**

**М.У.**